КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 27 февраль г.Казань № 136

2019 елга социаль түләүләр күләмен хисаплап чыгару өчен Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирлегендәге торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры кыйммәтен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2013 – 2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасы турында» 2012 ел, 14 июль, 717 нче карары белән расланган 2013 – 2020 елларга авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасына теркәлгән 13 нче кушымтада каралган Авыл җирлегендә яшәүче гражданнарның, шул исәптән яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең торак шартларын яхшырту өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләренә теркәлгән 1 нче кушымтаның 13 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Авыл җирлегендә яшәүче гражданнарның, шул исәптән яшь гаиләләрнең һәм яшь белгечләрнең торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләр күләмен хисаплап чыгару өчен Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирлегендәге торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры кыйммәтен 2019 елга 27 700,0 мең сум күләмендә расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин